КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 16 декабрь г.Казань № 1091

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турында» 2004 ел, 10 ноябрь, 480 нче карары белән белән расланган Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турында» 2004 ел, 10 ноябрь, 480 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 14 июнь, 265 нче; 2005 ел, 8 сентябрь, 442 нче; 2006 ел, 30 гыйнвар, 33 нче; 2007 ел, 29 гыйнвар, 22 нче; 2007 ел, 5 март, 70 нче; 2008 ел, 4 февраль, 61 нче; 2009 ел, 9 сентябрь, 628 нче; 2009 ел, 18 декабрь, 860 нчы; 2013 ел, 4 март, 144 нче; 2016 ел, 20 февраль, 106 нчы; 2017 ел, 3 июнь, 335 нче; 2018 ел, 1 сентябрь, 742 нче; 2020 ел, 30 октябрь, 976 нчы; 2021 ел, 21 июль, 630 нчы; 2021 ел, 15 сентябрь, 877 нче; 2021 ел, 30 декабрь, 1355 нче; 2023 ел, 20 февраль, 162 нче; 2023 ел, 21 март, 308 нче; 2023 ел, 3 июнь, 684 нче; 2024 ел, 16 гыйнвар, 10 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

17 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның финанс һәм матди ресурслары резервлары, әгәр әлеге резервларны булдыру һәм файдалану тәртибендә каралган булса, югары әзерлек режимы кертелгәндә файдаланылырга мөмкин.»;

19 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системада мәгълүмат белән тәэмин итү «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының автоматлаштырылган мәгълүмат-идарә итү системасы» дәүләт мәгълүмати системасын, шулай ук мәгълүмат бирүнең башка ысулларын кулланып гамәлгә ашырыла.»;

21 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе, җирле үзидарә органнары һәм территорияләрендә гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуы мөмкин булган яки килеп чыккан яисә вәкаләтләренә гадәттән тыш хәлләрне бетерү кертелгән оешмалар җитәкчеләре карарлары белән эшчәнлек алып баруның түбәндәге режимнарыннан берсе кертелергә мөмкин:»;

22 пунктта:

беренче абзацта «җитәкчеләре» сүзен төшереп калдырырга, «җирле үзидарә органнарының һәм оешмалар» сүзләреннән соң «җитәкчеләренең» сүзен өстәргә;

җиденче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар җитәкчеләре» сүзләрен «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмаларның җитәкчеләре» сүзләренә алмаштырырга;

23 пунктта татар текстында «җирле үзидарә органнары һәм оешмалар җитәкчеләре» сүзләрен «җирле үзидарә органнары һәм оешмаларның җитәкчеләре» сүзләренә алмаштырырга, «билгеләнгән» сүзен «кертелгән» сүзенә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин